| ГЛАВА<br>ТАТАРСКО-КАНДЫЗСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАТАР КАНДЫЗЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 декабрь 2021 ел Татар Кандызы авылы № 4

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлегенең Татар Кандызы авыл җирлегендә халык җыены үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.11, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Баулы муниципаль районы «Татар Кандызы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге башлыгы Карар итте:

1.Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлегенең Татар Кандызы авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2021 елның 17 декабрендә 08.00 сәгатькә билгеләргә. Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Татар Кандызы авылы, Подгорная урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан «Исламгалиевлар» крестьян - фермер хуҗалыгы конторасы-Гражданнар җыенын үткәрү урыны;
2021 елның 17 декабрендә 10.00 сәгатькә Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлегенең Татар Кандызы авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны-Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Татар Кандызы авылы, Совет

урамы, 168 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты һәм Татар Кандызы авылы гражданнары җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслау.: «2022 елда үзара салым кертүгә Сез Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Татар Кандызы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булмаган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, ләкин теркәлү урыны буенча өч елдан артык яшәмәгән затлардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан 300 сум күләмендә акча кертү белән килешәсезме?:

- Әхмәтҗанов, Гафиятуллин һәм Совет урамнары буенча агачлар һәм куаклар киселгән зиратлар территорияләрен төзекләндерү ;

- Татар Кандызы авылы урамнарында агачларны һәм куакларны кисү

"ӘЙЕ" "ЮК"

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге сайтында кабул ителгән көннән ун көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татар Кандызы
авыл җирлеге башлыгы М. Ш. Насыйбуллин